ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
*БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*
*БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
*БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН*
*БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*

---

КАРАР
РЕШЕНИЕ

18 май 2022 ел № 1-19

Буа шәһәр Советының 2014 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 1-39 номерлы «Физик затлар милкенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (Буа шәһәр Советының 21.05.2015 ел, №3-45, 09.10.2015 ел, №6-2, 14.11.2018 ел, №3-37, 24.06.2020 ел, №3-58 карарлары редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 31 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Буа шәһәр Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа шәһәр Советының 2014 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 1-39 номерлы «Физик затлар милкенә салым турында»гы карарына (Буа шәһәр Советының 21.05.2015 ел, №3-45, 09.10.2015 ел, №6-2, 14.11.2018 ел, №3-37, 24.06.2020 ел, №3-58 карарлары редакциясендә) ( алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Карарның 5 пунктындагы 1 пунктчасының 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза бирә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар бирергә хокуклы. Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан елның 1 ноябренә кадәр салым чоры булып торучы, әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым органына тапшырыла. Сайлап алынган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә,

шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа шәһәре башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов